# Шомырт чәчәкләре ак кына...

Марсель Гыймазетдинов

Хәтереңдәме, икәүләшеп безнең өй каршына пар шомырт агачы утырткан идек ул язны. Җыйнак кына ике чокыр казыдык, ашламалар да сиптек. Агач үсентеләре икебезнеке дә бер чамада иде. Син йөгерә-йөгерә аларга су сиптең: “Үссеннәр иде безнең пар шомыртлар”.-дидең.

Ничек булды соң әле, ул язны ничек таныштык соң әле без?

Әйе, син шәһәрдән эти-әниең туып-үскән авылга кунакка кайткан идең. Тугызынчы классны тәмамлаган идең ул елны син. Ә мин урта мәктәпне тәмамларга имтиханнарга әзерләнеп йөри идем.Мәктәптә уздырылган кичәдә мин сине вальс әйләнергә чакырдым. Мин оялчан идем ул чакларда: сүз башларга сүзләр эзләдем – таба алмадым. Шулай да барлык кыюлыгымны җыеп : “Сезне озатырга мөмкинме?” – дип сорый алдым. Син бер сүз дә әйтмәдең, бары, ике яңагыңны матур гына чокырайтып, елмайдың гына. Нәкъ шул минуттан бүгенге көнгә кадәр мин сине күңел түрендә иң нәфис, иң кадерле, иң саф хәзинә итеп саклап йөртәм. Минем өчен язның бу киче бүгенгә кадәр иң газиз кич булып калды. Бу кичтә минем, унҗиде яшьлек егетнең , сөю һәм сөюлү бөреләре ачылган, нәфис, беркем дә тияргә хакы булмаган нәни канатлар үскән иң матур , иң саф язгы кич иде.

Мин имтиханнарны уңышлы гына тәмамлап, өлгергәнлек аттестаты алдым. Ә син һәр имтиханнан соң мине тәбрикләдең, алдагыларына тагын да яхшырак әзерләнергә киңәшләр бирдең.

Без кичләрен һәрвакыт бергә булдык. Шомырт агачларына син һәр көнне су сиптең.

Нинди генә матур сүзләр эзләмәдем синең өчен. Барыбер  бик гади килеп чыга иде минем әйтәсе килгән тойгыларым. Син аларны бик тә якын итеп, яратып кабул итә торган идең. Инде менә имтиханнар да артта калды. Мин бүгеннән үз юлымны үзем сайларга: эшкә керергәме, укырга барыргамы – барысын да хәл итәргә тиеш идем.

Бергәләп болыннарда, ям-яшел бәбкә үләне белән капланган тау буйларында йөрдек: уйнадык, шаярдык, көлдек.

Хәтереңдәме, икәүләшеп киләчәк турында, Кармантау буенда бер-беребезне бүгенгедәй һәрвакыт яратырга, нинди генә авыр, кыен хәлләргә очрасак та, бер-беребезне ташламаска, киләчәктә, тиздәнме ул, әллә еллар узгачмы, бергә булырга сүз бирештек.

Безнең аерылышу киче дә килеп җитте. Бу кичне үзебез яраткан, безнең серләрне тыңлап торган һәм мәңгелеккә үзенә яшергән тау итәгендә утырдык.

Иртәгесен син киттең. Киттең, үзең белән минем йөрәгемне алып киттең. Үземне кая куярга белмичә, беркем белән дә очрашырга,сөйләшергә теләмичә, соңгы таңны каршылаган тау итәгендә утырган көннәрем күп булды.

Син минем иң беренче мәхәббәтем идең. Бу тойгылар, мондый җан әрнеткеч аерылышулар җир йөзендә яшәүче һәр кеше белән дә була торгандыр. Чөнки унҗиде яшьтә һәркем ярата, яратыла, һәркем аерылыша, һәркем мәңгелеккә ярата.

Беренче мәхәббәт – мәңгелек мәхәббәт. Әгәр беренче мәхәббәтең белән гомерлеккә бергә булмасаң, башка кеше белән тормыш корып, ничек кенә җиңел яшәсәң дә, кыен тормыш кичерсәң дә - барыбер беренче яраткан кешеңне оныта алмыйсың, син аны һич кенә дә искә төшермичә калмыйсың. Гомер буе үз-үзеңне мәҗбүр итеп , балалар хакына , сиңа яшьлеген , гомерен ышанып тапшырган кеше хакына яши бирәсең.

Без синең белән көн саен хат алышып тордык, көн, аның ничек узуы турында бер-беребезгә яза идек. Бик тә җылы, яшьлек хисе аңкып торган хатлар иде алар.

...Беренче сентябрь көнне мин – итститутка , син унынчы классска укырга бардык. Институт тормышы турында язып тормыйм, шатлык ташып торган, мәңгегә кабатланмас ул тормышта син үзең яшәдең.

Институтны тәмамлагач, мине күрше авылга укытучы итеп җибәрделәр. Бераз өс-башларны карап, чак кына акча туплагач, кышкы каникул вакытында синең янга, сөйгәнем янына шәһәргә очтым.

Хәтерлисеңме, син укый торган аудиториядә лекция бара иде. Мин ишек пыяласы аша сине эзләп таптым. Кинәт безнең күзләр: синең иң саф , аяз күк йөзедәй зәңгәр күзләрең белән, сагынып , сагыш катыш очрашу шатлыгы белән тулган минем кара күзләр очраштылар.

Синең яктан, чыгарылыш курс студенткасы тарафыннан, дорфа килеп чыкты чыгуын: кинәт кенә сикереп тордың да ишеккә ташландың. Билгеле, син соңыннан профессордан гафу үтендең. Профессор, эшнең нәрсәдә икәнен аңлады ды, күзлеген салып керсез елмаеп, синең аркаңнан йомшак кына сөйде: “ Яшь чакта минем белән дә андый хәлләр булганы бар иде”, - дип әйтүе иде чал чәчле профессорның.

Институт сезнең йорттан ерак булса да, җәяү кайтып киттек. Күбәләк карлар талгын гына бүрек-пальтоларга төшәләр дә, безнең ташып торган йөрәк җылысында эреп, юкка чыгалар. Әй, шатландык та соң без бу очрашуга! Әти-әниләрең дә , мине бик тә якын итеп, үз итеп каршы алдылар.

Икенче көн якшәмбе иде.Без ул көнне бергә үткәрдек: шәһәрне карадык, театрга бардык. Мин ул кичне сиңа тәкъдим ясадым. Син моңа бик шатланып риза булдың, ләкин институтны тәмамлап , диплом алгач, бергә булырбыз дип, мине юаттың, мин –синеке, бары синеке  дип, мине назладың. Мин ЗАГСка барып язылышырга , ә бергә тормыш итүне институт тәмамлагач , ягъни алты-җиде айдан соң барларбыз дидем. Без ул кичне төгәл бер карарга килә алмадык. Ничектер уен-көлке белән очлап куйдык.

Беләм, синең тәкъдимең дөрес иде. Җиде ел көткәнне , алты-җиде ай гына көтәрбез инде. Шулай да минем күңел төбендә нindидер бер ят төер калды.

Син – врач, сине – Саратов шәһәренең бер больницасына хирург итеп җибәрделәр. Бүлү комиссиясенә син: “Мин тормышка чыгам, мине Татарстанга җибәрегез”, - дип үтендең. Ләкин комиссия членнары синең үтенечеңне,  синең күз яшьләреңне исәпкә алмадылар. “Әгәр ул сине ярата икән, яныңа үзе килер”, - дип, эшне ансат кына хәл итеп куйдылар.

Эх, әгәр алты ай элек мине тыңлап, имтиханнарыңны бирер алдыннан ЗАГСка гариза биргән булсак...

Мине дә синең янга, Саратовка җибәрмәделәр. Кайчагында кайбер җитәкчеләр кеше күңелен аңламыйлар шул, кеше язмышын кырыс кына хәл итәләр.

Шулай итеп, ничектер җиңел генә язмышка буйсындык, тагын бераз көтәргә булдык.

“Язмыш” дигәнең әллә нинди нәрсә икән ул.Тагын без эшкә чумдык. Башта хатлар еш килсәләр дә, соңга таба сирәгәя башладылар. Аралар салкынаеп киткәндәй тоелды. Бу минем өчен бик тә авыр  хәл иде. Башта “вакыты юктыр, эшләре күптер”,- дип уйладым. Телефон аша сөйләшергә  чакырдым. Син телефон трубкасын алып: “Исәнме, сөйгәнем!” дип кенә әйттең дә, елый башладың. Син еладың, ни өчен, белмим. Мин аны бүгенге көнгә кадәр белмим. Тик син бу сөйләшүең белән йөрәгемне телгәләдең, гомерлеккә яра ясадың.

Хатлар килми башлады. Бер ай, өч ай җавап юк. Җәйге отпуск вакытында синең яныңа Саратовка киттем. Ләкин син ул вакытта Новосибирскида уздырыла торган яшь  врачлар семинарында идең...

Көзен чит телләр укытучы кызга өйләндем... Әллә ничек кенә килеп чыкты бу хәл. Ике ел бергә эшләп, бер-беребезне белгәнгәме, укытучылар алдында ярымшаярып ясаган тәкъдимемә риза булды ул кыз.

Минем өйләнүемне авылдагы иптәш кызларың аркылы ишеткәч, син кайттың. Ләкин соң иде инде. Миңа үзенең яшьлеген, сафлыгын ышанып тапшырган кешегә хыянәт итә алмыйм. Без синең белән күрештек, аңлаштык. Гаеп икебездә дә булган икән: гаепнең күбрәген үз өстемә алам. Чөнки хакыйкать шулай куша.

Саратовка китеп эшли башлаганыңа ике ай ярым узгач, әниең вафат булган. Бик зур кайгы кичергәнсең. Ник язмадың? Бу хәсрәт артыннан икенчесе: операция ясаганда кулыңны җәрәхәтләп , чир йоктыргансың, больницада бик авыр хәлдә яткансың. Озак яткансың син анда. Ник дус кызларың миңа язмадылар, ник соң дусларың миңа әйтмәделәр?. “Сине борчыйсым килмәде” дисең. Нигә мине, киләчәктә гомергә бергә булырга ант иткән, иң яраткан кешеңне борчымаска!? Бу борчу түгел ич, үзеңнең исәнлегеңне белдерү. Мин белмәдем, хатлар килми башлагач, врач врачны очраткандыр, бәлки безнең арада булган ярату чын ярату булмагандыр, чын ратканын очраткандыр дип уйладым. Гафу ит!

Ни өчен савыкканнан соң үзең язмадың?Мин язмаганга язмадым , дисеңме? Юк, алай кирәк түгел иде. Бәхет өчен, сөйгәнең өчен көрәшергә , горурлыгыңны бераз тезгенләргә кирәк иде...

Соң инде...

Бу синең өчен дә , минем өчен дә җан тетрәткеч фаҗига булды. Беләм, син пар шомырт агачларын сөя-сөя эчеңнән генә, кешегә күрсәтмичә еладың да , шул ук көнне авылдан киттең. Минем бөтен акыл-зиһенемне, йөрәгемне алып киттең.

Соң инде...

Сине ничек сөюемне тойган, гомерлеккә дип тормыш иптәше булган хатыным миңа: “ Гомер буена шулай әрнеп , газапланып яшәрсеңмени, балабыз юк чагында аерылышыйк, мин сине бик тә аңлыйм, син аны һичкайчан исеңнән чыгара, мине аны яраткан кебек ярата алмассың” – дип, берничә тапкыр тәкъдим ясады. Ул безнең : синең белән минем бәхетле булуыбыз өчен үзенең бәхетен корбан итәргә әзер иде. Нинди олы йөрәкле хатын! Мин аңа бу сүзләрне башка кабатламаска сүз бирдердем.

Бер елдан кызыбыз дөньяга килде. Хатыным аңа синең исемеңне куштырды.

Мин өйләнгәннән соң , әле син тагын өч ел кияүгә чыкмыйча, мине сагынып, мине көтеп яшәвеңне, егерме җиде тулып , егерме сигезенче яшь киткәч,

үзең теләгәнне очратуыңны да, улыгызга минем исемне кушуыңны да,  хәзер КамАЗда яшәгәнегезне дә беләм. Бәхет телим. Бәхетле бул...

Без әле дә шул авылда яшибез, эшлибез, ике бала үстерәбез. Әмма...

Мин авылыбызга кайткан саен икәүләп утыртып, су сибеп, карап үстергән пар шомырт агачы уртасында тирән уйга  чумып, унҗиде яшь чагыма кире әйләнеп кайтам... Ул агачлар зурлар инде. Ни дисәң дә , гомер уза, агачлар үсә: аларга бит бу язда унҗиде яшь тула. Ни өчендер мин утырткан агач синекенә караганда начаррак үсә. Утыртуым, кадерләвем җитенкерәмәгәндер, күрәсең. Ә синең сылуның ябалдашлары да киңрәк, чәчәкләре дә күбрәк, аның ап-ак чәчәкләре  минем агачныкына караганда соңрак та коела.

Һәр яз саен алар ап-ак чәчәккә төренә. Һәр яз саен бер - берсенә яз сәламе, яшьлек сәламе бирәләр. “Исән-сау кышладыгызмы?”- дип бер-берсенә гомернең соңгы көннәренә кадәр бергә үсәргә , бер-берсен җил-давылдан сакларга сүз бирешәләрдер кебек тоела.

Шулайдыр шул, аларга бит бу язда унҗиде яшь тула.

Унҗиде яшь…

